Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2023 елның 8 сентябре № 103

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советының «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыру тәртибе хакындагы нигезләмә турында» 2015 елның 26 маендагы 105 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Банклар һәм банк эшчәнлеге турында «Федераль законның 26 статьясына һәм «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында «Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 18.07.2022елның 18 июлендәге 472номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге Советының «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр урнаштыру тәртибе турында нигезләмә хакында» 2015 елның 26 маендагы 105 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.түбәндәге эчтәлекле 4.1 өлеш өстәргә:

«4.1. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр биргән зат акчаларны алуның законлылыгын раслый торган белешмәләрне «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә аларны юкка чыгару датасыннан 15 эш көне эчендә тапшыра."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Красновидово авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Красновидово авыл җирлеге Советы рәисе А.А. Болтаков